РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ БОЛЬШЕКИБЯЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422065, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Большие Кибячи, ул.Ф.Энгельса, 21
тел. (84362) 42-6-24

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КИБӘЧЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422065, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Олы Кибәче авылы, Ф.Энгельс урам, 21 йорт
тел. (84362) 42-6-24

e-mail: Bkib.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР
25.03.2019 №4

Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт
ителми торган биналарга, корылмаларга,
бүлмәләргә якын урыннар турында

1995 нче елның 22 нче ноябрендә кабул ителгән 171 нче номерлы «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләт тарафыннан тэртипкә салу турында» Федераль законның 16 нчы матдәсе нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 нче елның 27 нче декабрендә кабул ителгән 1425 нче номерлы «Алкогольле продукцияне ваклап сатарга ярамый торган гражданнарның күплэп җыелу урыннарын һәм югары дәрәҗәдәге куркыныч чыганаклары урнашу урыннарын Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләү, шулай ук алкогольле продукцияне ваклап сатарга ярамый торган кайбер оешмалар һәм объектлар янындагы чикләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү турында» карары нигезендә, алкогольле продукцияне ваклап сату һәм алкогольле продукцияне ваклап сату урыннары чикләрен билгеләү буенча вәкаләтләрне тапшыру турында төзелгән килешү нигезендә, иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләрен исәпкә алып,Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 1995 нче елның 22 нче ноябрендә кабул ителгән 171 номерлы «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләт тарафынннан тәртипкә салу һәм алкогольле продукцияне кулланyны (эчүне) чикләү турында» Федераль законның 16 нчы статьясындагы 2 нче пунктының 10 нчы пунктчасында күрсәтелгән биналарга, корылмаларга, бүлмәләргә якын булган территориядә алкогольле продукцияне ваклап сату 10 метр радиуста рөхсәт ителми.

2. Якын булган территория чикләрен исәплэү өчен өстәмә территория исәплэү тәртибен хисап нокталарыннан чыгып радиус буенча билгеләнә дип билгеләргә:

а) аерымланган территорияләр булган очракта - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 нче елның 27 нче декабрендә кабул ителгән 1425 нче номерлы «Алкогольле продукцияне ваклап сатарга ярамый торган гражданнарның күплэп җыелу урыннарын һәм югары дәрәҗәдәге куркыныч чыганаклары урнашу урыннарын

Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләү, шулай ук алкогольле продукцияне ваклап сатарга ярамый торган кайбер оешмалар һәм объектлар янындагы чикләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү турында" карары белән расланган Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмалар һәм объектлар чикләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү кагыйдәләренең (алга таба – кагыйдәләр буенча) 2 нче пунктында күрсәтелгән аерымланган территорияләргә йомыш белән килүчеләр өчен керү юлыннан;

б) кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгән оешмалар һәм (яки) объектлар урнашкан бинага (төзелешкә, корылмага) аерымланган территория булмаганда.

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге башкарма комитетына әлеге карар нигезендә күрсәтелгән Кагыйдәләрнең 2 нче пунктында күрсәтелгән һәр оешма һәм (яки) объект өчен якын булган территорияләрнең чикләре схемасын эшләргә һәм расларга.

4. Гражданнар күпләп җыела торган урыннарда районкүләм чаралар үткәрү вакытында алкогольле продукцияне ваклап сату Олы Кибәче авыл җирлеге Башкарма комитетының аерым карары белән регламентлана дип билгеләргә.

5. Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Саба районындагы территориаль бүлегенә, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Арча территориаль органына, Саба районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча Эчке эшләр бүлегенә федераль законнарның үтәлешен һәм әлеге карарның үтәлешен тикшереп торырга тәкъдим итәргә.

6. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советының 2017 нче елның 29 нчы ноябрендә кабул ителгән 27 нче номерлы «Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган биналарга, корылмаларга, бүлмәләргә якын урыннар турында турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/rus/ishtugan, җирлекнең информацион стендларында бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Олы Кибәче авыл җирлеге башлыгы: А.К. Сафин